КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 февраль г.Казань № 151

Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле

булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1032 нче; 2017 ел, 22 февраль, 113 нче; 2018 ел, 14 май, 354 нче, 2020 ел, 24 сентябрь, 863 нче, 2021 ел, 31 май, 422 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «(хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә күерүләрне исәпкә алып, хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарыннан тыш)» сүзләрен өстәргә;

9 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) сайлап алу үткәрү вакытлары, конкурста катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) бирә башлау яисә кабул итү тәмамлану датасын, ул конкурсы үткәрү турында игълан урнаштырылган көннең иртәгесеннән 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Татарстан Республикасында җирле үзидарәне аякка бастыруга һәм үстерүгә ярдәм итүгә, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре халкының социаль һәм икътисадый проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру максатларында финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирелә торган чыгымнарга түбәндәге чыгымнар керә:

а) чараларны матди-техник тәэмин итүгә;

б) төп чараларны сатып алуга;

в) эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә.»;

19 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«C = P_{мто} + P_{ос} + P_{у},»;$$

дүртенче - тугызынчы абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

20 пунктның «к» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«к) субсидия алучы тарафыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап (кварталга кимендә бер тапкыр), шулай ук субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү турында хисап һәм субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр турында хисап бирү тәртибе һәм сроклары;»;

20 пунктның «з» пунктчасында «тикшерүләр нәтиҗәләре буенча ачыкланган» сүзләрен «шул исәптән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган» сүзләренә алмаштырырга;

21 пунктның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Субсидия алучы Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең үрнәк рәвешенә кушып бирелә торган формалар буенча финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап, субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү турында хисап һәм субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр турында хисап тапшыра, шул исәптән:

финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап - хисап елының I, II, III һәм IV кварталларыннан соң килүче 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча;

субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү һәм субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләргә ирешү турында хисап - субсидия бирү елыннан соң килүче елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча. Әгәр субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе һәм субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр агымдагы финанс елның 31 декабреннән алдарак субсидия алучы тарафыннан ирешелсә, субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә һәм субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе ирешү өчен кирәкле күрсәткечләргә ирешү турында хисап субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә һәм субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешелгән хисап кварталының соңгы аеннан соң килүче 15 эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә.»;

24 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә һәм субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләргә ирешмәү.»;

27 пунктта «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 22 февраль, 151 нче
карары белән расланды

Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә, һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында гомуми таләпләр хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнгән һәм дәүләт (муниципаль) учреждениеләр булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне аякка бастыруга һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - сайлап алуда катнашучы).

2. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба - вәкаләтле орган) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидия бирүгә бюджет акчаларын алганчыга кадәр, гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче - вәкаләтле орган.

Субсидия турында белешмәләр Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - бердәм портал) тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын формалаштырганда «Бюджет» бүлегендә (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проекты) урнаштырыла.

3. Субсидияләр сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган айга кадәрге айның 1 числосына түбәндәге таләпләргә туры килә торган - сайлап алуда катнашучы бирелә:

сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе юк;

сайлап алуда катнашучының Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычы булмау;

сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучыга кушу, башка юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында түгел, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

сайлап алуда катнашучы чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты түгел;

сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртипнең 1 пунктында каралган максатка Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акчалар алучы булып тормый.

сайлап алуда катнашучы муниципаль берәмлекләрнең ирекле берләшмәсе булып тора, аның әгъзалары Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең 50 проценттан артыгы.

4. Сайлап алуны үткәрүне тәкъдимнәр (заявкалар) соратып алу юлы белән вәкаләтле орган гамәлгә ашыра. Сайлап алу, сайлап алуда катнашучының сайлап алу шартларына һәм сайлап алуда катнашуга тәкъдимнәр (заявкалар) керү чиратына туры килүеннән чыгып, сайлап алуда катнашучы өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәр (заявкалар) нигезендә үткәрелә.

5. Сайлап алуда катнашучы түбәндәге документларны үз эченә алган тәкъдимне (заявканы) вәкаләтле органга тапшыра:

Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре халкының социаль һәм икътисадый проблемаларын хәл итүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру проекты;

сайлап алуда катнашучы җитәкчесе тарафыннан расланган чыгымнар сметасын Татарстан Республикасында җирле үзидарәне аякка бастыруга һәм үстерүгә ярдәм итүгә, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре халкының социаль һәм икътисадый проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру максатларында, чыгымнарны финанс-икътисадый нигезләү кушымтасы белән;

әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча фактта башкарылган чыгымнарны раслый торган документлар (түләү документлары (түләү йөкләмәләре, керем һәм чыгым ордерлары), штат расписаниесе, локаль норматив актлар, хезмәт хакын исәпләү исемлекләре, хезмәт хакын тотып калу һәм исәпләү җыелмасы, салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына һәм (яисә) бюджеттан тыш дәүләт фондларына чыгымнарны каплауга заявка биргәндә тотып калу һәм исәпләүләр җыелмасы;

гамәлгә кую документларының күчермәләрен;

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 3 һәм 9 пунктлары белән билгеләнгән сайлап алу критериеләренә һәм таләпләренә туры килүе турында сайлап алуда катнашучы җитәкчесе имзалаган белешмә (ирекле формада);

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган тәкъдим (заявка), тиешле сайлап алу белән бәйле сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастыруга (урнаштыруга) ризалык;

сайлап алуны үткәрү планлаштырылган айдан алдагы айның 1 нче көненә бирелгән һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче (җыем түләүчесе, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салым, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар, процентлар, аны тутыру тәртибе һәм аны электрон формада тапшыру форматы турындагы белешмә формасын раслау турында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча, сайлап алуны уздыру аена кадәрге айның 1 нче көненә яисә хокукый акт белән билгеләнгән башка датага бирелгән салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч булмау турында салым органы белешмәсе.

Сайлап алуда катнашучы бу пунктның сигезенче – тугызынчы абзацларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, вәкаләтле орган күрсәтелгән документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Документлар сайлап алуда катнашучы тарафыннан кәгазьдә тапшырыла.

Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр, сайлап алуда катнашучы – вәкаләтле зат имзасы белән расланган һәм мөһере белән беркетелгән төзәтмәләрдән тыш, рөхсәт ителми. Кәгазьдә бирелгән тәкъдимнәрнең (заявкаларның) барлык битләре, сайлап алуда катнашучы вәкаләтле затның имзасы белән таныкланырга һәм әйләнештә тәкъдим (заявка) әйләнешендә гомуми саны күрсәтелеп, мөһер белән беркетелгән булырга тиеш.

Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны үткәрүгә бүлеп бирелгән срокларда тәкъдимне (заявканы) кире алырга хокуклы һәм кабат бирергә хокуклы. Бу чакта тәкъдим (заявка) кабат кергән көнне тәкъдимнәр (заявкалар) килү чираты тәртибендә теркәлә.

6. Вәкаләтле орган, сайлап алуны уздыру турында карар кабул ителгән көннән алып өч көн эчендә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бердәм

порталда һәм вәкаләтле органның рәсми сайтында (https://mert.tatarstan.ru/) сайлап алуны уздыру турында игълан урнаштыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары, шулай ук аларны үткәрү срокларын һәм тәртибен (кирәк булганда) күрсәтеп, сайлап алуның берничә этабын үткәрү мөмкинлеге турында мәгълүмат;

тәкъдимнәр (заявкалар) бирә башлау яки кабул итүне тәмамлау даталарын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

субсидия бирү нәтиҗәләре;

вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы һәм электрон почта адресы;

домен исеме, һәм (яисә) челтәр адресы, һәм (яисә) сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган бердәм порталда сайт битләре күрсәткече;

бу Нигезләмәнең 3 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә сайлап алу критерийлары;

тәкъдимнәр (заявкалар) бирү тәртибен һәм тәкъдимнәр (заявкалар) формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире алу тәртибен, тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире кайтару тәртибен, тәкъдимнәргә (заявкаларга) үзгәрешләр кертү тәртибен;

тәкъдимнәрне (заявкаларны) кабул итү һәм карау кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза кую вакытын;

субсидия бирү турында килешү төзүдән читләшкән сайлап алу җиңүчеләрен тану шартлары;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталда һәм Вәкаләтле органның рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы, ул сайлап алу җиңүчесен билгеләү көненнән соң килүче 10 календарь көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә.

7. Вәкаләтле орган тәкъдимнәр (заявкалар) кергән көнне аларны керү чираты тәртибендә журналга терки, аңа сан сугылырга, шнурланырга һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш.

Тәкъдимне (заявканы) теркәгәндә номерда аның керү датасына һәм вакытына күрсәтмә булырга тиеш;

8. Тәкъдимнәрне (заявкаларны) кабул итү тәмамланган көннән соң ике эш көне эчендә вәкаләтле орган сайлауда катнашучының әлеге Тәртипне сайлап алу критерийларына һәм таләпләренә туры килү-килмәвенә документларны карый, сайлап алу җиңүчесен билгели һәм субсидия бирү турында йә тәкъдимне (заявканы) кире кагу турында карар кабул итә.

Сайлап алуда катнашу өчен бер тәкъдим (заявка) дә тапшырылмаган очракта, сайлап алу уздырылмаган дип таныла.

9. Субсидия алучы түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:

субсидияне алучының гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) булып Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары тора;

субсидия алучының устав эшчәнлеге Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре халкының социаль һәм икътисадый проблемаларын хәл итүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән;

Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

10. Тәкъдимнәрне (заявкаларны) карап тикшерү стадиясендә тәкъдимен (заявкасын) алмау өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 9 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

тәкъдим ителгән тәкъдимнәр (заявкалар) һәм документларның сайлап алу үткәрү турында игъланда билгеләнгән таләпләргә (заявкаларга ) туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдимнәр (гаризалар) бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң тәкъдимнәр (гаризалар) бирү.

11. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннең иртәгесеннән соң килүче 10 календарь көннән дә соңга калмыйча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталда һәм вәкаләтле органның рәсми сайтында түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

тәкъдимнәрне (гаризаларны) карау датасы, вакыты һәм урыны;

сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат, тәкъдимнәр (гаризалар) каралды;

сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат, тәкъдимнәр (гаризалар) кире кагылган сәбәпләр, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турында игъланнар нигезләмәләре күрсәтелгән, аларга мондый тәкъдимнәр (гаризалар) туры килми;

субсидия бирү турында килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

12. Субсидия булган чыгымнарны (чыгымнарны), финанс белән тәэмин итү (каплау) чыганагы булып торучы чыгымнар (чыгымнар):

субсидия алучы хезмәткәрләренең хезмәт хакына чыгымнар (тотымнар);

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәсе бюджетына һәм (яисә) бюджеттан тыш дәүләт фондларына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган тәртиптә һәм шартларда салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр түләүгә чыгымнар (тотымнар).

13. Чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия күләме ($С_{ФО}$) чыгымнарны финанс белән тәэмин итү чыганагы әлеге Тәртипнең 12 пунктында билгеләнгән субсидия булган чыгымнар юнәлешләреннән чыгып түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_{ФО} = Р_{ОТ} + Р_{Н},$$

монда:

$Р_{ОТ}$ – субсидия алучы хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнары;

$Р_{Н}$ – хезмәт өчен түләү буенча түләүләрне исәпләү чыгымнары.

Субсидия алучы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнары расланган штат җәдвалы нигезендә хезмәткәрләрнең исәп-хисап саныннан, исәп-хисап вазыйфаи окладларыннан һәм тариф ставкаларыннан чыгып билгеләнә, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган башка түләүләрдән, субсидия алучының локаль норматив актларыннан чыгып билгеләнә.

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәсе бюджетына һәм (яисә) бюджеттан тыш дәүләт фондларына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган тәртиптә һәм шартларда салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр түләүгә чыгымнарны үз эченә ала.

Әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнарны каплауга субсидия ($С_{ВЗ}$) күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С_{ВЗ} = З_{ОТ} + З_{Н},$$

монда:

$З_{ОТ}$ – субсидия алучы хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә фактта тотылган чыгымнар;

$З_{Н}$ – фактта хезмәт хакы буенча түләүләргә исәпләнгән чыгымнар.

Субсидия алучы хезмәткәрләрнең хезмәт хакы өчен субсидияләр исәбеннән түләнергә тиешле чыгымнар, әлеге Тәртипнең 5 пунктының дүртенче абзацы нигезендә тапшырылган документларны, хезмәткәрләрнең исәп-хисап санын, хисаплы вазыйфаи окладларны һәм тариф ставкаларын исәпкә алып, расланган штат расписаниесе нигезендә түләүгә, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган башка түләүләрне, субсидия алучының локаль норматив актлары нигезендә факттагы чыгымнардан чыгып билгеләнә.

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәсе бюджетына һәм (яисә) бюджеттан тыш дәүләт фондларына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган тәртиптә һәм шартларда салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр түләүгә чыгымнарны үз эченә ала.

Субсидия алучы җитәкчесенең хезмәт хакы Татарстан Республикасы министры өчен билгеләнгән акчалата бүләкләүдән артмаган күләмдә билгеләнә. Субсидия алучы җитәкче урынбасарларының саны субсидия алучы хезмәткәрләренең гомуми штат санының 25 процентыннан артмаска тиеш, шул ук вакытта субсидия алучы җитәкче урынбасарларының айлык акчалата түләүләренең айлык җыелма күләме субсидия алучы җитәкчесенең айлык гомуми акчалата түләүләренең 0,9 күләменнән артмаска тиеш, субсидия алучы җитәкчесенең айлык гомуми күләме, «җитәкчеләр» категориясенә кертелгән башка вазыйфалар субсидия алучы җитәкчесенең айлык акчалата түләүләренең 0,5 күләменнән артмаска тиеш.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүгә юнәлдерелгән эшләрне турыдан-туры

башкаручы хезмәткәрләрнең хезмәт хакы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының үзәк аппаратларында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре вазыйфасы буенча акчалата түләү күләменнән арта алмый. Субсидия алучының штат расписаниесендә вазыйфаларны чагыштырып карау Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының үзәк аппаратларында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының түбәндәге категорияләре буенча башкарыла:

«структур бүлекчә җитәкчесе» вазыйфалары категориясе буенча - «бүлек башлыгы» вазыйфаларының төп төркеме, «бүлек башлыгы урынбасары» вазыйфаларының әйдәүче төркеме вазыйфасы дәрәҗәсеннән югарырак булмаган;

«белгеч» вазыйфалары категориясе буенча - «әйдәп баручы киңәшче» вазыйфаларның әйдәп баручы төркеме дәрәҗәсеннән югары түгел.

Техник хезмәт күрсәтүне (эшчеләрне) гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәт хакы бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган бюджет даирәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләре өчен билгеләнгән күләмдә, «йөртүче» категориясе буенча - Татарстан Республикасы бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренә 5 разрядтан югары булмаган күләмдә, «җыештыручы» категориясе буенча - Татарстан Республикасы бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәрендә хезмәт хакы 2 разрядтан артмаган күләмдә билгеләнә.

Субсидия алучының хезмәтенә түләү чыгымнары түбәндәгеләр исәбеннән билгеләнә:

субсидия алучының җитәкчесенә, җитәкче урынбасарларына һәм вазыйфалары «җитәкчеләр» категориясенә кертелгән хезмәткәрләргә елга 14 вазыйфаи оклад;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүгә һәм чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән эшләрне турыдан-туры башкаручы хезмәткәрләргә, арттыручы 1,445 коэффициентны исәпкә алып, елга 12 вазыйфаи оклад;

«машина йөртүче» категориясенә кертелгән эшчеләргә елга 16,8 тариф ставкасы;

«җыештыручы» категориясенә кертелгән эшчеләргә елга 15 тариф ставкасы.

Хезмәткәрләргә стимуллаштыру түләүләре квартал саен башкарыла.

Стимуллаштыручы түләүләр чыгымнары түбәндәге исәпләүләрдән билгеләнә:

җитәкче урынбасарларына һәм вазыйфалары «җитәкчеләр» категориясенә кертелгән хезмәткәрләргә 1 вазыйфаи оклад»;

субсидия бирү һәм чараларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсенә ирешүгә юнәлдерелгән эшләрне турыдан-туры башкаручы хезмәткәргә арттыручы 1,325 коэффициентны арттыруны исәпкә алып, 1 вазыйфаи оклад;

«машина йөртүче» һәм «җыештыручы» категорияләренә кертелгән эшчеләргә 1 тариф ставкасы.

14. Вәкаләтле орган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бердәм порталда һәм вәкаләтле органның рәсми сайтында сайлау нәтиҗәләре урнаштырылган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк форма буенча субсидия алучы белән субсидия бирү турында килешү төзи.

Субсидия алучы субсидия бирү турындагы килешүгә билгеләнгән сроктата кул

куймаса, субсидия алучы килешү төзүдән читләштерелгән дип санала.

Субсидияләр бирү турындагы килешүдә түбәндәгеләр каралган:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

субсидия булган чыгымнарны (чыгымнарны), финанс белән тәэмин итү (каплау) чыганагы булып торучы чыгымнар (чыгымнар);

субсидияләрне күчерү тәртибе һәм сроклары;

субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре;

әлеге Тәртипнең 18 пункты белән билгеләнгән формула буенча исәпләнелә торган штраф санкцияләрен куллану очракларын күздә тоткан шартлар;

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары вәкаләтле органга киметелгән очракта, субсидия бирү турындагы килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән килешеп булмаганда субсидия бирү турындагы килешүне өзү хакында, субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин булмавына китерә торган шарт;

вәкаләтле органның бурычы субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртиптә һәм субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүне уздыру;

субсидияләрне кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне (чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия алганда) сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю;

финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү тәртибе һәм сроклары, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү турында хисап;

хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыклары финанс белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тоткан шарт, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, күрсәтелгән чараларга ихтыяҗ булу яисә күрсәтелгән акчаларны кире кайтару турында карар кабул иткәндә, аларда әлеге Тәртипнең 19 пунктында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда ихтыяҗ булмаганда;

субсидия алучының, шулай ук субсидия алучылар (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, үзләренең устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнаша торган хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнаша торган коммерцияле оешмалардан тыш) белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның аларга карата вәкаләтле орган тарафыннан тикшерү үткәрүгә һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәүгә карата муниципаль финанс контролен башкаруга ризалыгы;

Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

15. Субсидия бирү елының 31 декабренә торышы буенча субсидия бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләр була:

Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре халкының социаль һәм икътисадый проблемаларын хәл итүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү, кимендә 35 чара;

муниципаль берәмлекләр съездын оештыру һәм уздыру, анда өстенлекле юнәлешләр, программалар, чаралар планнары билгеләнә, аларның үтәлеше турындагы хисаплар раслана, гамәлгә кую документлары нигезендә җитәкче органнар  сайлана һәм төзелә, кимендә бер съезд;

хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләрне исәпкә алып, эш хакы, матди бүләкләү һәм хезмәт өчен түләү буенча башка түләүләрне алган хезмәткәрләр саны, кимендә 15 кеше;

җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә проблемалы мәсьәләләр буенча дәүләт хакимияте органнарына җибәрелгән мөрәҗәгатьләр саны, кимендә 10 мөрәҗәгать;

җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең актуаль мәсьәләләре буенча эшләнгән методик материаллар һәм үрнәк муниципаль норматив актлар саны, кимендә сигез материал;

дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, юридик затларның һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау, кимендә 30 мөрәҗәгать;

Татарстан Республикасы законнары проектлары һәм федераль законнар проектлары буенча тәкъдимнәрне карау һәм кертү, кимендә 30 тәкъдим.

16. Вәкаләтле орган субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча субсидия алучының Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган субсидияләрне исәпләү счетларына яисә хәбәрчелек счетларына күчерә.

Субсидия алучы субсидия акчаларының керүенә һәм сарыф ителүенә аерым бухгалтер исәбен алып бара.

17. Субсидия алучы вәкаләтле органга Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән субсидияне тапшыру турында килешүнең үрнәк формасында кушымта итеп бирелә торган рәвешләр буенча, шул исәптән:

финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап - квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, IV квартал өчен хисап субсидия бирү елыннан соңгы 15 гыйнвардан да соңга калмыйча тапшырыла (чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия алганда);

субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү турында хисап, - квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, IV квартал өчен хисап субсидия бирү елының 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча тапшырыла.

Әгәр дә субсидия бирү нәтиҗәләре агымдагы финанс елның 31 декабреннән иртәрәк субсидия алучы тарафыннан бирелгән булса, субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү турындагы хисап субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешкән хисап кварталының соңгы аеннан соң килүче 15 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

18. Субсидияләр, вәкаләтле органның тиешле таләпләрен алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә - субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылган очракта;

тулы күләмдә - субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшырмаган очракта (чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия биргәндә);»;

тулы күләмдә - әлеге Тәртипнең 151 пунктында билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә җитмәгән очракта;

тулы күләмдә - субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү шартлары, максаты һәм тәртибе бозылган очракта, шул исәптән вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган очракта;

субсидиянең максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган күләмендә субсидия акчаларыннан максатчан файдаланмаган очракта.

Субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләре билгеләнмәгән очракта, вәкаләтле орган субсидия алучыга күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән алып биш эш көне эчендә мәҗбүри рәвештә хәбәр итеп, штраф санкцияләрен куллану турында карар кабул итә.

Штраф санкцияләре күләме (А) күрсәтелгән очракта түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$A = \left(\sum_{i=7}^{7} \left(1 - \frac{d_i}{D_i}\right) \times X\right) \times V,$$

монда:

i - субсидия бирү турында килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәләре саны;

di - субсидия бирү турында килешүдә күрсәтелгән субсидия бирүнең i-нчы нәтиҗәсенә ирешелгән мәгънәсет;

$D_i$ - субсидия бирү турында килешүдә күрсәтелгән субсидияне бирү i-нче нәтиҗәсенең планлы мәгънәсе;

X - хисап чорының соңгы көненә торышы буенча Россия Федерациясе Үзәк банкының төп ставкасына тигез тәгаенләүче коэффициент;

V – субсидия алучы тарафыннан алынган субсидия акчасы күләме.

Субсидия бирү нәтиҗәләренең берсен исәпләгәндә, планлы әһәмияткә ия булса, әлеге нәтиҗә буенча формуланың $\left(1 - \frac{d_i}{D_i}\right)$мәгънәсе нульгә тигез.

19. Хисап финанс елында чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, хисап финанс елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, вәкаләтле орган тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган юнәлешләргә ихтыяҗ булган очракта, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидия алучы вәкаләтле органга хисап финанс елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча шундый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Вәкаләтле орган әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат субсидия алучыдан алынган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, субсидия алучының агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калдык өлешен агымдагы финанс елына җибәрүгә ихтыяҗы булу яисә булмау турында карар кабул итә.

Вәкаләтле орган агымдагы финанс елында субсидия алучыга юллама ихтыяҗы булу турында карар кабул иткән очракта, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлеше вәкаләтле орган һәм субсидия алучы арасында мондый карар кабул ителгән көннән башлап календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидия бирү турында килешүгә өстәмә килешү төзелә.

20. Вәкаләтле орган субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидия алуга ихтыяҗы булу турында карар кабул иткән очракта, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлеше субсидия алучы финанс белән тәэмин итү чыганагы хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыгы булган чыгымнарны гамәлгә ашырырга хокуклы.

21. Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 18 һәм 18 пунктларында күрсәтелгән субсидияләрне кире кайтару срокларын бозганда, вәкаләтле орган, субсидия кире кайтарылу срогы чыккан көннән алып, эш көннәрендә исәпләп чыгарыла торган җиде көн эчендә күрсәтелгән акчаларны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

22. Вәкаләтле орган, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан әлеге Тәртиптә һәм субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүләр гамәлгә ашырыла.

23. Субсидиянең максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышын тикшерүдә тоту Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

___